| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| 422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39 | | 422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39 |

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001


| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
|---|---|
| 09.06.2020 | № 278 |

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кече яки өлкән яшьтән белем алу өчен балаларны кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законын, «Мәгариф турында»гы 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кече яки өлкән яшьтән белем алу өчен Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә балаларны кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибен расларга.

2. «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Г.Ф. Кирилинага муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кече яки өлкән яшьтән белем алу өчен балаларны кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибен җиткерергә.

3. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кече

яки өлкән яшьтән белем алу өчен балаларны кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибе турында»гы 2019 елның 15 февралендәге 111 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**

Тәтеш муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның 15 февралендәге
111 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кече яки өлкән яшьтән белем алу өчен балаларны кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибе**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең беренче классына алты яшь һәм алты айдан да кече яки сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итүгә рөхсәт бирүне җайга сала.

1.2. Әлеге тәртип түбәндәге норматив документлар нигезендә эшләнгән:

- «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ Федераль Закон;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында»гы 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы;
- «Мәгариф турында»гы 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;
- «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укуны оештыру шартларына һәм шартларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр». Санитар - эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар. СанПиН 2.4.2.2821-10.

1.3. Алты яшь  һәм алты айдан да кечерәк яки сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны, башлангыч гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең беренче сыйныфына кабул

итү бары тик «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ рөхсәте белән генә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

## 2. Эшне оештыру

2.1. Алты яшьтән кечерәк яки сигез яшьтән өлкәнрәк булган балаларны беренче сыйныфка кабул итүгә рөхсәтнамә, шулай ук беренче сыйныфка кабул итүдән баш тарту ата - аналардан (законлы вәкилләрдән) балаларны Тәтеш муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча иртәрәк яки аннан да соңрак укырга кабул итү турындагы гаризаларны карау комиссиясе бәяләмәсе нигезендә бирелә (алга таба - комиссия).

2.2. Комиссия «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы боерыгы белән төзелә. Комиссия составына медицина учреждениесе (1 кеше, килешенү буенча), мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләре (1 кеше, килешенү буенча), башлангыч гомуми белем бирү (1 кеше, килешенү буенча), «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба - мәгариф бүлеге) (2 кеше) вәкилләре керә. Комиссиянең эш предметы булып баланың мәктәптә укуга әзерлеген билгеләү тора.

2.3. Комиссия үз эшен ел саен, 1 февральдән 15 сентябрьгә кадәр башкара.

2.4. Муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең беренче классына алты яшь һәм алты айдан да кечерәк яки сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итүгә рөхсәт алу өчен ата-аналар (законлы вәкилләр) 1 һәм 2 кушымталар нигезендә муниципаль гомуми белем бирү учреждениесенә гариза бирергә тиеш. Гариза агымдагы елның 5 сентябреннән дә соңга калмыйча тапшырыла һәм гаризалар кабул итү журналында муниципаль гомуми белем бирү учреждениесенең җаваплы заты тарафыннан теркәлә.

2.5. Гариза баланың ата-анасы (законлы вәкиле) паспортын күрсәткәндә кабул ителә. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

- туу турында таныклык күчермәсе;

- баланың законлы вәкиле (уллыкка алучы, опекун) вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе;

- баланың психологик әзерлеген раслый торган документ күчермәсе (психиатрдан белешмә яки ПМПК бәяләмәсе, беренче сыйныф укучысының старт дәрәҗәсен өйрәнү нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә);

2.6. Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар теркәлү узганнан соң өч эш көне эчендә комиссиягә карауга җибәрелә.

2.7. Гаризаны карау һәм комиссия карарын кабул итү вакыты-гаризаны теркәгәннән соң 10 эш көненнән дә артмый.

2.8. Комиссия тискәре карарны бала сәламәтлеге торышы буенча медицина күрсәткечләре булганда кабул итә.

2.9. Комиссия карары нигезендә һәм законнар нигезендә, мәгариф бүлеге гаризаны теркәгәннән соң 10 эш көне эчендә беренче сыйныфка кабул итүгә рөхсәт бирү яки беренче сыйныфка кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә.

2.10. Беренче сыйныфка алты яшь һәм алты айдан да кечерәк яки сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итүгә рөхсәт алынганнан соң, муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе югарыда күрсәтелгән балаларны Россия Федерациясе законнары һәм муниципаль гомуми белем бирү учреждениесендә расланган кабул итү кагыйдәләре нигезендә беренче сыйныфка кабул итә.

2.11. Беренче сыйныфка алты яшь һәм алты айдан да кечерәк яисә сигез яшьтән өлкәнрәк балаларны кабул итүдән баш тарткан очракта, муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе бер эш көне эчендә ата-аналарга (законлы вәкилләргә) укуга кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итә.

2.12. Мөрәҗәгать итүче (ата-ана) гамәлдәге законнар нигезендә район комиссиясе гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кече яки өлкән яшьтән белем алу өчен балаларны кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Мәктәп директоры_________________

_________________________

Адрес:

Телефон:

ГАРИЗА

Минем баланы ______________________________________________________

(фамилиясе, исеме, туган көне)

___________________________________________________________МБГББУ

(муниципаль гомуми белем бирү учреждениесенең исеме)

иртә яшьтә ____ яшь _____ айда кабул итүне рөхсәт итүегезне сорыйм.

Гаризага түбәндәге документларны терким:

- туу турында таныклык күчермәсе;

- баланың законлы вәкиле (уллыкка алучы, опекун) вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе;

- баланың психологик әзерлеген раслый торган документ күчермәсе (психиатрдан белешмә яки ПМПК бәяләмәсе, беренче сыйныф укучысының старт дәрәҗәсен өйрәнү нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә);

- башка документлар ____________________________________________

Муниципаль гомуми белем бирү оешмасына балаларны иртә яшьтә кабул итү шартлары белән таныштым.

«___» _____________ 20___ ел __________

(имза)

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кече яки өлкән яшьтән белем алу өчен балаларны кабул итүгә рөхсәт бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Мәктәп директоры___________________

___________________________

Адрес:

Телефон:

ГАРИЗА

Минем баланы ___________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, туган көне)

_______________________________________________________________МБГББУ

(муниципаль гомуми белем бирү учреждениесенең исеме)

соңрак яшьтә ____ яшь _____ айда кабул итүне рөхсәт итүегезне сорыйм.

Баланың элек булем алмавының сәбәбе: ______________________________

Гаризага түбәндәге документларны терким:

- баланың законлы вәкиле (уллыкка алучы, опекун) вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе;

- баланың психологик әзерлеген раслый торган документ күчермәсе (психиатрдан белешмә яки ПМПК бәяләмәсе, беренче сыйныф укучысының старт дәрәҗәсен өйрәнү нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә);

- башка документлар _____________________________________________

«___» _____________ 20___ ел __________

(имза)